КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2018 ел, 7 август | г.Казань | № 642

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 122 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 октябрь, 794 нче; 2017 ел, 24 ноябрь, 898 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча конкурс комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан Ф.С.Габделганиевны, А.Э.Калайданы, Е.В.Муравьеваны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Шадриков<br>Александр Валерьевичны | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын, конкурс комиссиясе рәисен |
| Газиев<br>Наил Хәмид улын | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы экспертын (килешү буенча) |
| Минакова<br>Елена Анатольевнаны | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын (килешү буенча). |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәтен оештыру турында» 2017 ел, 21 апрель, 234 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте багланышларын тәэмин итү буенча координация советы (алга таба – совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

совет составыннан Г.Ю.Вафинны, А.А.Здуновны, А.Ә.Нәзировны, Э.Н.Фәттаховны, М.З.Шакировны чыгарырга;

совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Борһанов Рафис Тимерхан улын | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улын | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре» ассоциациясе рәисен (килешү буенча) |
| Кузюров Равил Әфраим улын | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрын |
| Садыйков Марат Наил улын | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын |
| Фәттахов Дамир Илдус улын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре буенча министрын |
| Шадриков Александр Валерьевичны | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын; |

Ф.С.Габделганиев  вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы икътисад министры»;

В.А.Леонов вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы спорт министры, Координация советы рәисе урынбасары».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин